ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 апрель 2025ел № 2531

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, аларның кеременең һәм мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, 2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең максималь күләме – 55 413 сум 92 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 2 006 154 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 4 012 308 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 6 018 462 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 8 024 616 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 10 030 770 сум;

- алты кешедән торган гаилә өчен – 12 036 924 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 14 043 078 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 16 049 232 сум.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов